ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 19 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш); 2025, № 18 (I өлеш), № 33 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 2 өлешендә:

а) $15^{2}$ пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«$15^{2}$) Федераль законның $71^{1}$ статьясындагы 6 өлешендә каралган компенсация түләү тәртибен, аның күләмен билгеләү һәм аны Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибен билгеләү;»;

б) түбәндәге эчтәлекле $15^{4}$ пункт өстәргә:

«$15^{4}$) Федераль законның $71^{2}$ статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә каралган штраф түләү тәртибен, Федераль законның $71^{2}$ статьясындагы 5 өлешендә каралган компенсация түләү тәртибен, аларның күләмнәрен билгеләү һәм аларны Татарстан Республикасы бюджетына күчерү тәртибен билгеләү;»;

2) 17 статьяның 2 өлешендә:

а) беренче абзацта «үткәрүне һәм» сүзләрен «үткәрүне,» сүзенә алмаштырырга, «кабул итүне» сүзләреннән соң «, шулай ук югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар студентларының студент билетлары

турында һәм зачет кенәгәләре турында белешмәләр, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары, аспирантурада фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча укуны раслый торган башка документлар турында белешмәләр бирүне» сүзләрен өстәргә;

б) 1 пунктта «үткәрүне һәм» сүзләрен «үткәрүне,» сүзенә алмаштырырга, «кабул итүне» сүзләреннән соң «, шулай ук югары белем бирү мәгариф оешмалары һәм фәнни оешмалар студентларының студент билетлары турында һәм зачет кенәгәләре турында белешмәләр, ординатура программалары, ассистентура-стажировка программалары, аспирантурада фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча укуны раслый торган башка документлар турында белешмәләр бирүне» сүзләрен өстәргә;

3) 20 статьяда:

а) 1 өлештә «граждан» сүзен «Россия Федерациясе гражданы, әгәр Федераль законда яисә Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса,» сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә «күләмендә» сүзеннән соң «эшкә урнаштыру буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә максатчан укыту турында шартнамәне берьяклы тәртиптә өзгән өчен» сүзләрен өстәргә;

в) 7 өлештә «компенсацияне түләү» сүзләрен «эшкә урнаштыру буенча йөкләмәләрне үтәмәгән яисә максатчан укыту турында шартнамәне берьяклы тәртиптә өзгән өчен компенсация түләү» сүзләренә алмаштырырга, «бирү тәртибе» сүзләреннән соң «, максатчан укыту турында яңа шартнамә төзү тәртибе» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 3 пунктларыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 һәм 3 пунктлары 2026 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2026 ел, 21 февраль
№ 9-ТРЗ